**Эчтәлек**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
города Набережные Челны
«Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по художественно-эстетическому направлению развития воспитанников №95 «Балкыш»

Яр Чаллы шәһәрнең «Балкыш» 95 нче балаларның эстетик-зәвык үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомуми үстерелеше балалар бакчасы"
МУНИЦИПАЛЬ АВТОНОМИЯЛЕ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ

423814, Республика Татарстан, г. Набережные Челны, ул. Ахметшина, дом 113 Тел/факс 8 (8552) 58-90-23

СОГЛАСОВАНО
Председатель Совета педагогов
МАДОУ «Детский сад № 95 «Балкыш»
________________ Еричева Г.А.
«28» августа2015г.

УТВЕРЖДАЮ
Заведующий МАДОУ
«Детский сад № 95 «Балкыш»
________________ Яруллина Е.Х.
«28» августа2015г.

Обсуждено на педагогическом совете
Протокол №1 от «28» августа2015г.

Введена в действие
Приказ №55 от «28» августа2015г.

# ПРОГРАММА

## Скоро в школу!

## познавательно-речевого направления развития воспитанников 3-7 лет раздел «Әкиятләр илендә»

**Автор: Амирова Гульсияр Раисовна, воспитатель по обучению детей татарскому языку высшей квалификационной категории**

**г. Набережные Челны**
**2015 год**

**Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре**
**95 санлы "Балкыш" балалар бакчасының югары категорияле тәрбиячесе**
**Әмирова Гөлсөяр Рәисовна төзегән "Әкиятләр илендә"**
**дип исемләнгән өстәмә белем бирү программасына**
**рецензия**

Безнең республикада өйрәтү-тәрбия эшен ана телендә оештыру һәм үткәрү мәгариф өлкәсендә дәүләт политикасының мөһим бер принцибы булып тора. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның эстетик, әхлак, акыл тәрбиясен тормышка ашыру, аларның максатчан рәвештә сөйләмен үстерү, халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләргә, милли мәдәниятка кызыксыну уяту, алар аша зәвыклык тәрбияләү һәм үстерү, иҗади сәләтләрен камилләштерү әһәмиятле проблемаларның берсе. Әхлак, эстетик, акыл тәрбиясе нигезләре мәктәпкәчә чорда салына һәм алар күпчелек очракта баланың коммуникатив һәм социомәдәни үсешен билгели. Бу аспектлардан караганда Әмирова Г.Р. төзегән түгәрәк программасының эшләнүе аеруча зарури.

Рецензияләнә торган программаның төгәл структурасы бар: аңлатма язуыннан, эчтәлектән, кулланган әдәбият исемлегеннән, кушымтадан тора. Аңлатма язуында программа авторы сәләтле балалар белән эшләү үзенчәлекләрен билгели, сайлаган программаның актуальлелеген яктырта, дәүләт телләренә өйрәтү буенча өйрәтү-методик комплектның эчтәлеген үзләштерү буенча экиятләрне сәхнәләштерү эшен оештыра. Эчтәлек ягына килгәндә, "Әкиятләр илендә" дип исемләнгән түгәрәк программасы 2 елга планлаштырылган перспектив планнан һәм календарь-тематик планнан тора. Программада сәнгатьлелек алымнарына өйрәтүдән тыш, Гөлсөяр Рәисовна әхлак сыйфатлар тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Бай кушымта бирелгән. Эшләнгән конспектлар нигезендә татар, рус халык, автор әкиятләре ята. Конспектлар грамоталы итеп, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып язылган. Әкият эчтәлеге балаларны милли мәдәниятка җәлеп итүдә зур роль уйный. Эшчәнлек конспектлары кызыклы, мавыктыргыч, тирән эчтәлекле, милли колоритны исәпкә алып төзелгән. Музыкаль, хәрәкәтләнү, сөйләм, сүрәтләү эшчәнлекләре бергә алып барыла. Сөйләм үсешенә аеруча игътибар ителә. Сәхнәләштерү эшчәнлеген шулай оештыру балаларның алган белемнәрен, осталыкларын системалаштырырга, гомумиләштерергә ярдәм итә. Болар барысы да төрле милләт вәкиле булган балаларның үз-үзен тоту культурасын тәрбияләү, туган телне ярату, халык иҗатына кызыксыну үстерү, олыларны хөрмәт итү, кешелеклелек, дуслык, мәрхәмәтлелек, кече күңеллелек, кеше хәленә керә белү кебек әхлакый сыйфатлар тәрбияләү бурычларын чишү белән дә бәйле.

"Балкыш" балалар бакчасы тәрбиячесе Әмирова Г.Р. төзегән "Әкиятләр илендә" дип исемләнгән түгәрәк программасы милли өйрәтү һәм тәрбияләү учреждениеләрендә эшләүче педагоглар, тәрбиячеләр, студентлар өчен гамәли яктан әһәмиятле, зарури. Куллануга тәкъдим ителә.

Рецензент:
Яр Чаллы педагогика университеты,
педагогик фәннәр кандидаты,
З.Т. Шәрәфетдинов ис.
педагогика һәм психология кафедрасы доценты — И.Ж. Хәбибуллина
02. 10. 2017 ел.

Хәбибуллиной И.З.
Начальник канцелярии
Дата 03.10. 2017

ИСХОДЯЩИЙ №412
"24" мая 2010 г

# Рецензия
## программу «Экиятлэр илендэ»
## воспитателя по обучению татарскому языку первой квалификационной категории МА ДОУ №95 «Балкыш» города Наб.Челны
## Амировой Г.Р.

Программа «Экиятлэр илендэ» построена на принципах методического центризма, деятельностного подхода.

Программа составлена с учетом реализации связей по разделам:

-ознакомление с художественной литературой,

-словесно-дидактические игры,

-связная речь,

-драматизация,

-настольный, пальчиковые театры

В представленной работе актуальность заявленной проблемы автор рассматривает через призму влияния сказок на формирование личностных качеств ребенка дошкольного возраста. И тем самым обосновывает следующие аспекты:

- формировать творческое мышление, культуру общения;
- полученные в процессе чтения сказок знания переносить в практику своей работы;
- развивать связную речь;
- развивать творческое воображение, сообразительность, самостоятельность.

Автор прослеживает изменения и усложнения происходящие с личностными качествами ребенка в различные периоды дошкольного детства, определяет тематики различных мероприятий по знакомству со сказками, примерный объем по отдельным темам, примерный диапозон развития интересов детей, перспективно-тематический план, конспекты разных видов деятельности.

Программа является подтверждением того, педагог МАДОУ №95 «Балкыш»
Амирова Г.Р. работает в режиме инновационных технологий.

Кандидат педагогических наук,
доцент ИНПО
17.05. 10 г.

З.М.Зарипова

**ОТЗЫВ**
**о сотрудничестве факультета дошкольного воспитания ФГБОУ ВПО «Набережночелнинский институт социально-педагогических технологий и ресурсов» с МАДОУ «Детский сад № 95 «Балкыш»**

Сотрудничество с образовательным учреждением – важная традиция действующей системы подготовки педагогических кадров. Студенты с охотой спешат в детские сады и школы, в том числе в МАДОУ детский сад № 95 «Балкыш». В 2010 году коллектив детского сада приобщился к городскому проекту «Учитель–мастер». Студенты НИСПТР получили возможность участвовать в работе уникальных мастерских в качестве наблюдателей и экспертов.

Особый интерес вызывают ежегодные тематические фестивали новаторских идей – где участники мастер-класса публично представляют тематические проекты, нацеленные на решение различных управленческих и образовательных задач ДОУ. Работа мастерских активно отражается в интернет ресурсах, что позволяет широкому кругу специалистов и студентов приобщаться к творческому сообществу.

Инициатор и руководитель проекта Яруллина Екатерина Хуснеевна, заведующий МАДОУ побуждает к увлекательному сотворчеству слушателей, ежегодно помогая обрести уверенность десяткам коллег. Гостей Балкыш очаровывает обстановка творческого поиска, заинтересованность в успехе коллег характерная для коллектива. Каждый педагог - участник общего дела и каждый носитель одного из приоритетных направлений.

Закирова Резеда Назгатовна, старший воспитатель – мастер, организатор, координатор идей, вдохновитель коллективных проектов, профессиональный эксперт педагогической документации.

Рамазанова Миляуша Наилевна, воспитатель высшей квалификационной категории, учитель-мастер 2010 – обаятельная, заразительно улыбающаяся, автор-сочинитель песенного материала для приобщения детей к говорению на татарском языке, рукодельница, художница, настоящая наставница для молодых коллег и неиссякаемый источник вдохновения для опытных педагогов.

Песигина Ольга Николаевна, педагог-логопед первой квалификационной категории. Занятия в её мастерской отметили особой заботой о комфорте для слушателей, окруженные уютом и увлекательным учебным процессом, слушатели к концу курса предложили особо оригинальные проекты, готовые к воплощению в жизнь.

Ваничкова Александра Гакилевна, музыкальный руководитель высшей квалификационной категории, обязательный участник всех форумов, на правах ответственной хозяйки зала. Умелый ассистент и помощник педагогов-мастеров в сотрудничестве с Амировой Гульсияр Раисовной, воспитателем по обучению татарскому языку высшей квалификационной категории вносят неповторимый стиль в работу коллектива, демонстрируют организаторский и профессиональный опыт, который хочется перенять.

Гостеприимно готовы поделиться опытом работы с коллегами Киршина Ирина Николаевна, воспитатель первой квалификационной категории, Еричева Галина Анатольевна, воспитатель высшей квалификационной категории, Утнюхина Резида Исмагиловна воспитатель первой квалификационной категории, Сафиуллина Файруза Накиповна воспитатель первой квалификационной категории, Ляпунова Мария Викторовна воспитатель первой квалификационной категории, Шагиева Олеся Владимировна, педагог-психолог.

Отражая впечатления о Балкыш, студенты отмечают, что хотели бы работать в таком коллективе. Отрадно встречать среди слушателей мастер-классов выпускников НИСПТР, которые отмечают, участие в работе мастер-классов – достойное продолжение процесса профессионального становления, возможность открыть в себе новый творческий потенциал, найти новые пути самоутверждения в отрасли.

Декан факультета дошкольного воспитания
канд.пед.наук Л.В. Рахматуллина

Заведующий кафедрой дошкольной и социальной педагогики
канд.пед.наук, доцент Т.Ф. Бабынина

МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Отдел делопроизводства

1. Эчтәлек.......................................................................................................2

2. Аңлатма язуы...............................................................................................3-4

3. Перспектив план...........................................................................................5

4. Календарь – тематик план..........................................................................6-9

5. Кушымта.......................................................................................................10

6. Кулланылган әдәбият....................................................................................20

**Аңлатма язуы**

“Әкиятләр илендә” программасы 95 “Балкыш” балалар бакчасында тормышка ашырыла. Әлеге программа 3-5 яшьтәге балалар өчен ике елга каралган.

“Әкиятләр илендә” программасында сәләтле балалар белән эшләү төрле әкиятләр, шигырьләр, җырлар, уеннар, театр, сәхнә әсәрләре ярдәмендә яңа УМКына кергән биремнәр аша алып барыла.

Әлеге программа сәләтле балаларны әкиятләр аша халкыбызның элеккеге тормышы, гореф-гадәтләре, хайваннар дөньясы , тылсымлы әкият геройлары белән очраштыра. Балалар белән әкиятләрне сәхнәләштереп, геройларның эчке дөньясы, кичерешләре турында фикер алышып, әңгәмәләр үткәрү әкиятләрнең эчтәлеген тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Әдәби әсәр балаларны татар телендә иркен сөйләшергә, аралашырга өйрәтә. Тел өйрәнүгә мотивация тудыра. Логик фикер йөртү сәләтен үстерә. Туган телгә ихтирам тәрбияли. Матур әдәбият әсәрләре балаларны әхлакый һәм эстетик яктан дөрес тәрбияләргә эттәргеч бирә.

Балаларның тормышын уеннарсыз күз алдына китерүе кыен. Уен балаларны кызыксындыра, иҗатын үстерә. Әкиятләрне милли татар халык уеннары белән үреп алып бару балаларга татар телен һәм ана телен тагы да яхшырак үзләштерергә ярдәм итә, яңа белемнәр алырга стимул тудыра. Уеннар балаларда үз көчеңә ышану, кумәклек, ярдәмләшү кебек сыйфатлар тәрбияли. Сәхнәләштерелгән әкиятләрне милли уеннар белән үрелеп баруы балаларда уңай тэисир тудыра, сүзлек байлыгын арттыра.

**Программаның максаты.**

Балаларның белемнәрен УМКына кергән әкиятләр, мультфильмнар, җырлар ярдәмендә баету.

**Программаның бурычлары.**

1.Балаларны театр төрләре, сәхнә әсәрләре, әкият геройлары белән таныштыру.

2.Татар халык әкиятләре, уеннары, җырлары, шигырьләре ярдәмендә диалогик, монологик, ягъни бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сүзлек байлыкларын арттыру. Фонематик ишетү сәләтен үстерү.

3. Әкиятләр һәм уеннар белән танышу барышында балаларның татарча сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү.

4. Татар халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү.

5. Г.Тукай, М.Җәлил, А.Алиш иҗатларына кызыксыну, горурлык хисләре уяту, әкиятләренә мәхәббәт тәрбияләү.

6. Татар халык уеннары, җыр һәм матур әдәбият аша татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту, балаларда дуслык мөнәсәбәтләре тәрбияләү.

7. Кыюлык, югалып калмау сыйфатлары тәрбияләү.

8. Бер-береңә карата дустанә мөнәсәббәт, ярдәмләшү, киңәшләшү кебек сыйфатлар тәрбияләү.

9. Балалар күңелендә телебезгә, гореф-гадәтләребезгә, халкыбызга хөрмәт; тарихыбызга, туган ягыбызга кызыксыну уяту.

**Программаның яңалыгы.**

Программа балаларга әкияттә булган персонаж характерлары кичерешләрен уйнап, геройларның әңгәмәләрен ятлап сөйләп көндәлек тормышта татарча аралашырга, сөйләшергә чакыра. Җайлаштырылган әкиятләр аша тел өйрәнүгә мотивация тудыра.

**Программаның актуальлеге.**

Сәләтле бала күзәтүчән, кызыксынучан, кешеләр белән тиз аралашучан булып үсә. Шуңа күрә сәләтле балаларның әйләнә-тирә дөньяга күзаллавын мөмкин кадәр күбрәк киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү, логик фикер эшчәнлеген арттыру өстендә эшләү зарури. Баланың тел белән кызыксыну мотивациясен югалтмаска кирәк. Өстәмә эшчәнлектә бала акыл эшчәнлеген баета. Хәтер, уйлау, фикерләү сәләтен үстерә. Матур әдәбият әсәрләрен сөйләргә өйрәнә. Сөйләмендә тулы һәм ким җөмләләр куллана башлый. Тормышта алган белемнәрен, күнекмәләрен куллана.

**Көтелгән нәтиҗә.**

Сәхнә әсәрләре ярдәмендә балаларның диалогик сөйләм телен хәтер, уйлау сәләтен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Төрле халыкның милли әкиятләре белән танышып, аларны сәхнәдә үзләрен иркен тотып, матур уйнауларына, сәхнәләштерүләренә ирешү. Балалар бакчасындагы бәйрәм – кичәләрендә татарча дөрес, сәнгатьле чыгыш ясауларын булдыру.

**Программаның тормышка ашырылуы.**

Сәләтле балалар белән эшчәнлек татар телен өйрәтүче тәрбияче тарафыннан атнага 1 тапкыр сентябрь аеннан алып май ахырына кадәр татар теле кабинетында яки музыка залында үткәрелә. Әлеге өстәмә эшчәнлектә

ата-аналар теләкләре буенча анда катнаша, шулай ук спектакльләргә костюмнар әзерләү белән булышалар.

**Программаның арттырып үтәлеше.**

- Татар теленә генә хас авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтергә һәм сөйләмдә кулланырга юнәлтү.
- Сәхнә әсәрләренең эчтәлеген кыскача һәм тулы итеп сөйли белү.
- Әкияттә кулланылган шигырьләрне, җырларны, табышмакларны, мәкальләрне көндәлек кулланышка кертүгә басым ясау.
- Г.Тукайның, М.Җәлилнең, А.Алишның әсәрләрен һәм татар, рус халык әкиятләрен сәхнәләштерүгә ирешү.
- Шәһәр күләмендә уздырылган конкурсларда һәм бәйрәм – кичәләрдә дөрес, сәнгатьле чыгыш ясауларына ирешү.

**Диагностика.**

Елга 3 тапкыр сентябрь, гыйнвар, май айларында үткәрелә.

**Материаль – техник әсбаплар.**

Эшчәнлекләрне үткәрү өчен түбәндәге ярдәмлекләр һәм җиһазлар кирәк: УМКы әсбаплары, компьютер, проектор, экран, магнитофон; компьютер программалары, презентацияләр, дисклар; рәсемнәр, картиналар; уенчыклар, муляжлар; җәнлек костюмнары, милли күлмәкләр, камзуллар, яулыклар, калфаклар, түбәтәйләр, читекләр; битлекләр; өстәл, бармак театрлары; дидактик, хәрәкәтле, өстәл, милли уеннар атрибутлары; ярдәмлекләр.

**Балалар белән эш.**

- УМКы әсбаплары материалларын куллану.
- “Шалкан”, “Йомры икмәк”, “Төремкәй”, “Батыр әтәч”, “Үги кыз”, “Өч кыз”, кебек әкиятләр сәхнәләштерү.
- Әкиятләр буенча презентацияләр карау.
- Автор уеннарын уйнау.
- «Заман» компьютер программасын куллану.
- «Габдулла Тукай», «Сабантуй», «Татар халык әкиятләре» һ. б. мультимедия әсбаплардан файдалану.
- Татарча җырларга, биюләргә, әкиятләргә язылган дисклар, аудиоязмалар, аларга презентацияләр куллану.
- Әкиятләрне сөйләү, үзгәртү, сәхнәләштерү.
- Өстәл, бармак театрлары күрсәтү.
- Милли уеннар, җырлар, шигырьләр өйрәнү.
- Проектлар төзү.

**Ата-аналар белән эш.**

- Ел башында һәм ахырында һәр төркем ата-аналары белән анкета тутыру.

- Ел дәвамында сәләтле балалар белән эшләнәсе һәм эшләнгән эшләр турында консультацияләр уздыру.
- Бергә костюмнар әзерләү.
- Ачык ишекләр көне уздыру.
- Балалар бакчасында ата-аналар һәм балалар белән берлектә “Балкыш” календаре буенча уздырылган бәйрәмнәрдә сәнгатьле чыгыш ясарга булышу.

**“Әкиятләр илендә” өстәмә шөгыльләрнең перспектив планы.**

(беренче уку елы)

| № | Ай | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Сентябрь. | “Шалкан” әкияте.<br>*(Рус халык әкияте буенча)* | 4 |
| 2 | Октябрь. | “Йомры икмәк” әкияте.<br>*(Рус халык әкияте буенча)* | 4 |
| 3 | Ноябрь. | “Төлке, Куян һәм әтәч” әкияте.<br>*(Лев Толстой буенча)* | 4 |
| 4 | Декабрь. | “Төремкәй” әкияте.<br>*(Рус халык әкияте буенча)* | 4 |
| | | Сәхнәдә чыгыш ясау. | 1 |
| 5 | Гыйнвар. | «Батыр әтәч» әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 4 |
| 6 | Февраль. | “Үги кыз” әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 4 |
| 7 | Март. | “Өч кыз” әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 3 |
| 8 | Апрель. | Тукай әкиятләре – күңелдә. | 4 |
| 9 | Май. | “Сертотмас үрдәк” әкияте.<br>*(Абдулла Алиш буенча)* | 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | Экскурсия.<br>«Без театрга барабыз». | 1 |

**“Әкиятләр илендә” өстәмә шөгыльләрнең перспектив планы.**

(икенче уку елы)

| № | Ай | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Сентябрь. | “Кәҗә бәтиләре һәм бүре” әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 4 |
| 2 | Октябрь. | “Куян кызы” әкияте.<br>*(А.Алиш әкияте буенча)* | 4 |
| 3 | Ноябрь. | “Өч аю” әкияте<br>*(Рус халык әкияте буенча)* | 4 |
| 4 | Декабрь. | “Кем нәрсә ярата?”әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 4 |
| | | Сәхнәдә чыгыш ясау. | 1 |
| 5 | Гыйнвар. | “Сәяхәтче әтәч” әкияте<br>*(курчак театры)* | 4 |
| 6 | Февраль. | Җәлил абый шигырьләре. | 4 |
| 7 | Март. | “Батыр әтәч” әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 3 |
| 8 | Апрель. | Тукай әкиятләре – күңелдә. | 4 |
| 9 | Май. | “Кем көчле” әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 4 |
| | | Экскурсия.<br>«Без театрга барабыз». | 1 |

## Календарь тематик план.

| Ай | Тема | Атна | Максат | Методик алым |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь. | “Шалкан” әкияте. *(Рус халык әкияте буенча)* | 1 | Балаларны театр сәнгате белән таныштыру. «Шалкан» рус халык әкияте белән таныштыру. | 1. «Күңелле туп» уены. Балалар белән танышу. 2. Рус халык әкиятен уку. 3.“Тычкан салыш” уены. |
| | | 2 | «Шалкан» әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау. | 1.Презентация карау. 2.Әкият геройларының холыкларын күрсәтү. 3.«Мин нәрсә?» дид.уен. 4.“Тычкан салыш” уены. |
| | | 3 | Балаларны өстәл театры белән таныштыру. | 1.Өстәл театры күрсәтү. 2.Фикер алышу. 3.“Тычкан салыш” уены. |
| | | 4 | Балаларны «Шалкан» әкиятен сәхнәдә матур, сәнгатьле уйнауларына ирешү. | 1.Әкиятне сәхнәләштерү. 2. Бәя бирү. 3.Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| Октябрь. | “Йомры икмәк” әкияте. *(Рус халык әкияте буенча)* | 1 | “Йомры икмәк” рус халык әкияте белән таныштыру. | 1.«Матур чәчәк» уены. 2. Рус халык әкиятен уку. 3.“Тирмә” башкорт уены. |
| | | 2 | “Йомры икмәк” әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау. | 1.Презентация карау. 2.Әкият геройларының холыкларын күрсәтү. 3.«Мин нәрсә?» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | дид.уен. |
| | | 3 | Балаларны өстәл театры белән таныштыру. | 1.Кашык театры кую.<br>2.Фикер алышу.<br>3.“Тирмә” башкорт уены. |
| | | 4 | Балаларны сәхнәдә иркен тотып, матур уйнауларына ирешү, персонаж диалоглары буенча сәнгатьле сөйләү күнекмәләрен булдыру. | 1.Әкиятне битлекләр киеп сәхнәләштерү.<br>2. Бәя бирү.<br>3. Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| Ноябрь. | “Төлке, Куян һәм әтәч” әкияте.<br>*(Лев Толстой буенча)* | 1 | “Төлке, Куян һәм әтәч” әкияте белән таныштыру. | 1.«Сары яфрак» уены.<br>2.Рус халык әкиятен уку.<br>3.“Буш урынлы” уены. |
| | | 2 | “Төлке, Куян һәм әтәч” әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау. | 1.Презентация карау.<br>2.Әкият геройларын күрсәтү.<br>3.«Мин нәрсә?» дид.уен. |
| | | 3 | Балаларны өстәл театры белән таныштыру. | 1.Курчак театры күрсәтү.<br>2.Фикер алышу.<br>3. “Буш урынлы” уены. |
| | | 4 | Л.Толстой әкиятен сәхнәдә балаларның үзләрен иркен тотып, матур уйнауларына ирешү. | 1. Үзгәртелгән әкиятне сәхнәләштерү.<br>2. Бәя бирү.<br>3.Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| Декабрь. | “Төремкәй” әкияте.<br>*(Рус халык әкияте буенча)* | 1 | “Төремкәй” рус халык әкияте белән таныштыру. | 1. «Кар бөртекләре» уены.<br>2.Рус халык әкиятен уку.<br>3.“Ак куянкай” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | жырлы-уен. |
| | | 2 | “Төремкәй” әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау. | 1.Презентация карау.<br>2.Әкият геройларының холыкларын күрсәтү.<br>3.«Мин нәрсә?» дид.уен.<br>4.“Ак куянкай” жырлы-уен. |
| | | 3 | Балаларны бармак театры белән таныштыру. | 1. Бармак театры кую.<br>2. Фикер алышу.<br>3. “Ак куянкай” жырлы-уен. |
| | | 4 | Әкиятен сәхнәдә дөрес, матур уйнауларына ирешү. | 1. Үзгәртелгән әкиятне сәхнәләштерү.<br>2. Бәя бирү.<br>3.Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| | | 5 | Әти-әниләргә сәхнәдә чыгыш ясау. | |
| Гыйнвар. | «Батыр әтәч» әкияте. *(Татар халык әкияте буенча)* | 1 | «Батыр әтәч» татар халык әкияте белән таныштыру. | 1. «Чебиләр зарядкасы» уены.<br>2.Татар халык әкиятен уку.<br>3. «Чыпчыклар һәм оялар» мари халык уены. |
| | | 2 | «Батыр әтәч» әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау. | 1. Презентация карау.<br>2. Әкият геройларын күрсәтү.<br>3. «Мин нәрсә?» дид.уен. |
| | | 3 | Балаларны өстәл театры белән таныштыру. | 1. Конус театры күрсәтү.<br>2. Фикер алышу.<br>3. «Чыпчыклар һәм оялар» мари халык |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | уены. |
| | | 4 | Балаларны «Батыр этәч» әкияте геройларын сәхнәдә матур уйнауларына ирешү. | 1. Әкиятне сәхнәләштерү.<br>2. Бәя бирү.<br>3. Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| Февраль. | “Үги кыз” әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 1 | “Үги кыз” татар халык әкияте белән таныштыру. | 1. “Үги кыз” уены. Миңлебай уенын үзгәртеп.<br>2.Татар халык әкиятен уку.<br>3. «Җиләк җыям» җырлы уен. |
| | | 2 | “Үги кыз” әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау. | 1. Презентация карау.<br>2. Әкият геройларын күрсәтү.<br>3. «Мин нәрсә?» дид.уен. |
| | | 3 | Балаларны сәхнәдә үз-үзләрен матур тотып уйнауларына ирешү, персонаж диалоглары буенча сәнгатьле сөйләү күнекмәләрен булдыру. | 1. Үзгәртелгән әкиятне сәхнәләштерү.<br>2. Бәя бирү.<br>3. Фикер алышу.<br>4. Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| Март. | “Өч кыз” әкияте.<br>*(Татар халык әкияте буенча)* | 1 | “Өч кыз” татар халык әкияте белән таныштыру. | 1. «Мияу-мияу нинди төс» уены.<br>2.Татар халык әкиятен уку.<br>3. «Әпипә» җырлы-бию. |
| | | 2 | “Өч кыз” әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау аларны сәхнәдә күрсәтә белү. | 1. Презентация карау.<br>2. Әкият геройларын күрсәтү.<br>3. «Мин нәрсә?» дид.уен. |
| | | 3 | “Өч кыз” әкияте | 1.Әкият |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | буенча персонаж диалогларын сәнгатьле сөйләү күнекмәләрен булдыру. | геройларының холыкларын битлекләр киеп күрсәтү<br>2.Диалог төзү.<br>3.«Әпипә» җырлы-бию. |
| | | 4 | Балаларны “Өч кыз” әкиятен сәхнәдә матур, сәнгатьле, дөрес сәхнәләштерүләренә ирешү. | 1.Әкиятне сәхнәләштерү.<br>2. Бәя бирү.<br>3.«Әпипә» җырлы-бию.<br>4. Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| Апрель. | Тукай әкиятләре – күңелдә. | 1 | Г.Тукай иҗаты белән таныштыру. | 1. «И туган тел» җыры.<br>2. Иҗатын сөйләү.<br>3. Рәсемнәрен карау.<br>4. Шигырьләрен уку. |
| | | 2 | Иҗаты буенча иллюстрацияләрдән әкиятләрне танып белү. | 1. Презентация карау.<br>2.“Кызыклы шәкерт”.<br>3.“Бала белән күбәләк”.<br>4.Су анасында кунакта. «Тарак» уены. |
| | | 3 | Г.Тукай буенча булган белемнәрен ныгыту. | 1. Шигырьләрен сөйләү.<br>2. Бәя бирү.<br>3.Су анасында кунакта. «Тарак» уены. |
| | | 4 | Г.Тукай иҗатын сөйли белү, персонаж диалоглары буенча сәнгатьле сөйләү күнекмәләрен булдыру. | 1.Әкият күрсәтәбез. Су анасында кунакта. «Тарак» уены.<br>3. Фикер алышу.<br>4.Бүләккә әкият рәсеме. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Май. | “Сертотмас үрдәк” әкияте. *(Абдулла Алиш буенча)* | 1 | “Сертотмас үрдәк” әкияте белән таныштыру. | 1.«Кояш» уены.<br>2. А.Алиш әкиятен уку.<br>3. «Чума үрдәк, чума каз»уены. |
| | | 2 | “Сертотмас үрдәк” әкияте белән танышуны дәвам итү. Әкият геройларының холыкларын тасвирлау. | 1.Презентация карау.<br>2.Әкият геройларын күрсәтү.<br>3. «Мин нәрсә?» дид.уен.<br>4.Әкиятне үзгәртү. |
| | | 3 | Балаларны өстәл театры белән таныштыру. | 1.Шәүлә театры кую.<br>2.Фикер алышу.<br>3. «Чума үрдәк, чума каз»уены. |
| | | 4 | Балаларны “Сертотмас үрдәк”әкиятен сәхнәдә матур уйнауларына ирешү. | 1.Үзгәртелгән әкиятне сәхнәләштерү.<br>2. Бәя бирү.<br>3. Бүләккә буялмаган әкият рәсеме. |
| | Экскурсия. «Без театрга барабыз» | 5 | Балаларны татар театр сәнгате белән таныштыру. | Татар драм театрында балалар өчен спектакль карау. |

## *«Шалкан» әкиятенә ияреп.*

*(Рус халык әкияте буенча)*

Катнашалар: Автор, шалкан, бабай, әби, Алсу, Акбай, мәче, тычкан.

Җиһазлау. Өй, шалкан, костюмы, эт, мәче, тычкан, күбәләк костюмнары, бабай, әби киемнәре, лейка, иләк, күбәләк, тота торган җәтмә, чәчәкләр.

Сәхнәдә өй тора, өй янында «бакча»: агачлар, яшелчә, чәчәкләр беркетелә. Автор сөйләгәндә персонажлар сәхнә аша үтәләр.

Автор. Бер матур авылда әби белән бабай яши. Аларның эте, мәчесе, кечкенә тычканнары да бар. Әбинең оныгы Алсу шәһәрдә яши. Ул һәр җәй авылга кунакка кайта.

Яз көне бабай бакчада шалкан чәчә. *(Бабай иләк тотып, «шалкан чәчеп» үтә)*

Җәй көне Алсу шалканга су сибә, чүбен утый. *(Кыз бу вакытта хәрәкәтләр белән күрсәтеп тора)*

Шалкан зур булып үсә. *(Шалкан булып киенгән бала иплэп кенә чүгәләп утыра)*

Менә бер көнне бабай шалканны алырга бакчага чыга.

Бабай. Уф! (маңгаен сөртеп)
Шалкан ничек зур булган
Ай – һай, уңыш бик уңган. (тарта)
Бер, ике, өч,
Һич җитми көч!

- Карчык, әй карчык.

Әби. Нәрсә?

Бабай. – Бик зур булган шалканым. Карчык, әйдә шалкан йолкырга! *(тарталар)*

Икесе бергә. Бер, ике, өч,
Һич җитми көч!

Әби. Мин чакырыйм Алсуны үзебезнең кызкайны. Кызым, әйдә шалкан йолкырга!

Кыз. Хәзер әбием киләм.

Барысы да. Бер, ике, өч,
Һич җитми көч!

Кыз. Мин чакырыйм маэмайны, безнең Акбай бик көчле. Акбай, әйдә шалкан йолкырга!

Акбай. Һау-һау, хәзер киләм.

Барысы да. Бер, ике, өч,
Һич җитми көч!

Акбай. Мин чакырыйм мәчене, безнең мәче бик көчле. Мәче, әйдә кырга, шалкан йолкырга!

Мәче. Мияу-мияу хәзер киләм.
Барысы да. Бер, ике, өч,
Һич җитми көч!
Мәче. Мин чакырыйм тычканны, бик тә көчле күршене. Тычкан, әйдә , шалкан йолкырга!
Тычкан. Пи-пи-пи.
Мин тычкан бик кечкенә,
Күзләрем яхшы күрә,
Көчем бик күп булганга,
Сезгә ярдәмгә киләм.
Барысы. 1,2,3. Бездә дуслык, бездә көч!
Бабай. – Бик зур булган шалканым. Сыйланыгыз, дусларым.

## ***"Йомры икмәк" әкиятенә ияреп.***

*(Рус халык әкияте буенча)*

Катнашалар: Автор, бабай, әби, йомры икмәк, куян, бүре, аю, төлке.

Автор. Борын-борын заманда бер карт белән карчык яшәгән. Аларның балалары булмаган.

Беркөнне бабай келәттән он алып керә. Әби оннан йомры икмәк ясый да мичкә салып пешереп, тәрәзә төбенә суынырга куя. Йомры икмәк күзләрен ачада урманга таба тәгәрәп китә.

Йомры икмәк. Мин барам, барам, барам
Урманга барам, барам
Әйе шул, әйе шул,
Урманга барам, барам.
Автор. Каршысына куян килеп чыга.
Куян. Ой, ой, ой йомры икмәк, мин сине ашыйм.
Йомры икмәк. Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм.
Куян. Я, җырла.
Йомры икмәк. Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган,
Кызу мичтә пешкән.
Мин бабайдан качтым,
Мин әбидән качтым,
Синнән дә качам,
Синнән дә качам.
Автор. Шулай итеп тәгәрәп китеп барган йомры икмәк. Каршысына бүре килеп чыга.
Бүре. Уууу, йомры икмәк, мин сине ашыйм.
Йомры икмәк. Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм.

Бүре. Я, җырла.
Йомры икмәк. Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган,
Кызу мичтә пешкән.
Мин бабайдан качтым,
Мин әбидән качтым,
Мин куяннан качтым
Синнән дә качам.
Автор. Шулай итеп тәгәрәп китеп барган йомры икмәк. Каршысына аю килеп чыга.
Аю. О йомры икмәк, мин сине ашыйм.
Йомры икмәк. Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм.
Аю. Я, җырла.
Йомры икмәк. Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган,
Кызу мичтә пешкән.
Мин бабайдан качтым,
Мин әбидән качтым,
Мин куяннан качтым,
Мин бүредән качтым,
Синнән дә качам,
Синнән дә качам.
Автор. Шулай итеп тәгәрәп китеп барган йомры икмәк. Каршысына төлке килеп чыга.
Төлке. Ай, яй, яй, йомры икмәк, мин сине ашыйм.
Йомры икмәк. Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм.
Төлке. Я, җырла.
Йомры икмәк. Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган,
Кызу мичтә пешкән.
Мин бабайдан качтым,
Мин әбидән качтым,
Мин куяннан качтым,
Мин бүредән качтым,
Мин аюдан качтым,
Синнән дә качам,
Синнән дә качам.
Төлке. Ай, яй, яй, йомры икмәк, бигрәк матур җырлыйсың. Якынрак килеп җырла әле. Колакларым ишетми.
Йомры икмәк. Мин келәттән себерелгән,
Каймакка басылган,
Камырдан ясалган,

Кызу мичтә пешкән.
Мин бабайдан качтым,
Мин әбидән качтым.

*Төлке йомры икмәкне кочаклый да , йомры икмәк кача.*

Төлке. Ам. Ай, яй, яй, йомры икмәк, ай яй тәмле икмәк. Ммммм, тәмле.

Автор. Шуның белән әкияттә тәмам,
Кемнәр яхшы тыңлаган, булдырган,
Зур үскән, әйбәт булган.

## ***“Төлке, Куян һәм әтәч” әкиятенә ияреп.***

*(Лев Толстой буенча)*

Катнашалар: Автор, төлке, куян, эт, аю, үгез, бүре, әтәч.

Автор. Бер матур урманда төлке һәм куян яшәгәннәр. Куянның өе булган ди кайрыдан. Төлкенеке боздан. Яз җиткән. Кояш җылыта. Тамчы тама. Чәчәкләр үсә. Төлкенең өе эрегән. Ул куяннан бер генә көнгә кундыруын сорап кунакка кергән.

Төлке. Куян, куян, мине бер генә көнгә кунарга керт әле.
Автор. Куян аны керткән. Ә төлке аны куып чыгарган. Куян елый-елый чыгып киткән. Аның каршысына бер эт очраган.
Эт. Һау-һау-һау. Сәлам куян.
Куян. Сәлам Акбай.
Эт. Куян, куян, нигә елыйсың?
Куян. Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, төлкенеке боздан иде. Ул мине өемнән куып чыгарды.
Эт. Елама куян, мин аны куып чыгарырмын.
*Өй кырына килә.*
Эт. Һау-һау-һау. Төлке, төлке, чык бар кит.
Төлке. Балта кайрыйм, пычак кайрыйм. Сикереп төшәрмен дә, өзгәләп ташлармын.
*Эт калтырап, куркып китеп бара.*
Эт. Һау-һау-һау.

*Куян тагын елый. Аның каршысына бер аю очраган.*
Аю. У-у-у. Сәлам куян.
Куян. Сәлам Аю дус.
Аю. Куян, куян, нигә елыйсың?
Куян. Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, төлкенеке боздан иде. Ул мине өемнән куып чыгарды.
Аю. Елама куян, мин аны куып чыгарырмын.
*Өй кырына килә.*
Аю. У-у-у. Төлке, төлке, чык бар кит.

Төлке. Балта кайрыйм, пычак кайрыйм. Сикереп төшәрмен дә өзгәләп ташлармын.
*Аю калтырап, куркып китеп бара.*
Аю. У-у-у.

*Куян тагын елый. Аның каршысына бер үгез очраган.*
Үгез. Му-му-му.Сәлам куян.
Куян. Сәлам Үгез.
Үгез. Куян, куян, нигә елыйсың?
Куян. Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, төлкенеке боздан иде. Ул мине өемнән куып чыгарды.
Үгез. Елама куян, мин аны куып чыгарырмын.
*Өй кырына килә.*
Үгез. Му-му-му.Төлке, төлке, чык бар кит.
Төлке. Балта кайрыйм, пычак кайрыйм. Сикереп төшәрмен дә өзгәләп ташлармын.
*Үгез калтырап, куркып китеп бара.*
Үгез. Му-му-му.

*Куян тагын елый. Аның каршысына бер бүре очраган.*
Бүре. У-у-у.Сәлам куян.
Куян. Сәлам Бүре.
Бүре. Куян, куян, нигә елыйсың?
Куян. Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, төлкенеке боздан иде. Ул мине өемнән куып чыгарды.
Бүре. Елама куян, мин аны куып чыгарырмын.
*Өй кырына килә.*
Бүре. Уу-у-у.Төлке, төлке, чык бар кит.
Төлке. Балта кайрыйм, пычак кайрыйм. Сикереп төшәрмен дә өзгәләп ташлармын.
*Бүре калтырап, куркып китеп бара.*
Бүре. Му-му-му.

*Куян тагын елый. Аның каршысына бер әтәч килеп чыга. Кулында чалгысы да бар.*
Әтәч. Кикерикүк. Кикерикүк. Сәлам куян.
Куян. Сәлам Әтәч.
Әтәч. Кикерикүк. Куян, куян, нигә елыйсың?
Куян. Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, төлкенеке боздан иде. Ул мине өемнән куып чыгарды.
Әтәч. Елама куян, мин аны куып чыгарырмын.
*Өй кырына килә һәм тыпырдый.*
Әтәч. Кикерикүк.Төлке, төлке, чык бар кит. Кулымда минем чалгы.
Төлке. Хәзер, хәзер. Аягыма гына киим.
*Тагы да катырак тыпырдый.*

<u>Әтәч.</u> Кикерикүк.Төлке, төлке, чык бар кит. Кулымда минем чалгы.
<u>Төлке.</u> Хәзер, хәзер. Тунымны гына киим.
*Әтәчнең бөтенләй ачуы килә.*
<u>Әтәч.</u> Кикерикүк. Кикерикүк. Төлке, төлке, чык бар кит. Кулымда минем чалгы. Хәзер яныңа керәм дә өзгәләп ташлыйм.
*Төлке  куркып китеп бара.*
<u>Автор.</u> Шуннан бирле бу матур өйдә куян белән әтәч матур гомер итәләр.

## ***«Төремкәй» әкиятенә ияреп.***

*(Рус халык әкияте буенча)*

<u>Катнашалар:</u> Тычкан, бака, керпе, куян, тиен, төлке, бүре, аю, Алсу.

<u>Автор.</u> Бер матур басуда бер төремкәй тора. Анда беркемдә яшәмәгән.Урман аша шунда кузгалыйк.
Мин барам урманнан
Як-ягыма каранам.
Тирә-як бик матур,
Мин шуңа сокланам.

*Тычкан чыга. Төремкәйне күрә.*
<u>*Тычкан*</u> : Чи- чи- чи.Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
*(Төремкәйгә керә яши башлый.)*

*Бака чыга. Төремкәйне күрә.*
<u>*Бака:*</u> Ква-ква- ква.Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
-  Ә син кем?
- Мин бака. Бака – бакылдык.
- Әйдә, кер.

*Керпе чыга. Төремкәйне күрә.*
<u>*Керпе:*</u> Фр-фр-фр.Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
- Мин бака. Бака – бакылдык.
<u>*Бергә:*</u>   -  Ә син кем?
- Мин керпе. Кечкенә керпе.
- Әйдә, кер.

*Куян чыга. Төремкәйне күрә.*
<u>*Куян:*</u>   Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
- Мин бака. Бака – бакылдык.
- Мин керпе. Кечкенә керпе.

*Бергә:* Ә син кем?

- Мин куян. Куркак куян.

*Бергә:* Әйдә, кер.

*Куркак куян сөенә аларны уенга чакыра.*

*Куян:Әйдәгез, бергә уйнап алабыз.*

Ак куянкай утыра
Колакларын селкетә
Менә шулай, менә шулай
Колакларын селкетә.

*Тиен чыга. Төремкәйне күрә.*

*Тиен:* Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
- Мин бака. Бака – бакылдык.
- Мин керпе. Кечкенә керпе.
- Мин куян. Куркак куян.

*Бергә:* Ә син кем?

- Мин тиен. Җитез тиен.

*Бергә:* Әйдә, кер.

*Төлке чыга. Төремкәйне күрә.*

*Төлке:* Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
- Мин бака. Бака – бакылдык.
- Мин керпе. Кечкенә керпе.
- Мин куян. Куркак куян.
- Мин тиен. Җитез тиен.

*Бергә:* Ә син кем?

- Мин төлке. Хәйләкәр төлке.

*Бергә:* Әйдә, кер.

*Төлке аларны биергә чакыра.*

*Төлке:* *Әйдәгез, бер биеп алыйк.*

Бар монда зур төлке.
Зур төлке, матур төлке.
Төлке, төлке кил әле,
Биеп-биеп кит әле.

*Бүре чыга. Төремкәйне күрә.*

*Бүре:* Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
- Мин бака. Бака – бакылдык.
- Мин керпе. Кечкенә керпе.
- Мин куян. Куркак куян.
- Мин тиен. Җитез тиен.
- Мин төлке. Хәйләкәр төлке.

*<u>Бергә</u>:*  Ә син кем?

- Мин бүре. Соры бүре.

*<u>Бергә</u>:*  Әйдә, кер.
*Бүре бик ачыккан, аны чәй белән сыйлыйлар.*

*Аю чыга. Төремкәйне күрә.*
*<u>Аю</u>:*  Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
- Мин бака. Бака – бакылдык.
- Мин керпе. Кечкенә керпе.
- Мин куян. Куркак куян.
- Мин тиен. Җитез тиен.
- Мин төлке. Хәйләкәр төлке.
- Мин бүре. Соры бүре.

*<u>Бергә</u>:*  Ә син кем?

- Мин аю. Зур аю.

*<u>Бергә</u>:*  Әйдә, кер.
*Аю аларның барсында уенга чакыра.*
*Аю: Әйдәгез бергә-бергә минем арттан кабатлагыз.*
Зур аю атлап бара
Лып-лып-лып, лып-лып-лып.
Күзләрен йомып ала
Леп-леп-леп, леп-леп-леп
Як-ягына карана
Аннары биеп ала.

*Алсу чыга. Төремкәйне күрә.*
*<u>Алсу</u>:*  Төремкәй!  Төрем, төрем, төремкәй. Төремкәйдә кем яши?
- Мин тычкан. Тычкан – чыелдык.
- Мин бака. Бака – бакылдык.
- Мин куян. Куркак куян.
- Мин тиен. Җитез тиен.
- Мин төлке. Хәйләкәр төлке.
- Мин бүре. Соры бүре.
- Мин аю. Зур аю.

*<u>Бергә</u>:*  Ә син кем?
- Мин Алсу. Татар кызы.
- Әйдәгез, чыгыгыз монда бергәләп җыр җырлап, күңел ачабыз.

<u>Җырлы-биюле уен “Минем өем”</u>
Тәрбияче: Бергәләп басыйк әле,
Әкияттә яшәүчеләрне
Искә төшерик әле.
Монда яши тычкан,
Мин тычкан.
Монда яши бака,

Мин бака.
Монда яши куян,
Мин куян.
Монда яши төлке,
Мин төлке.
Монда яши бүре,
Мин бүре.
Монда яши аю,
Мин аю.
Бергә: Әйе шул, әйе шул,
Бу өй матур,
Бу өй зур.

## *“Үги кыз” әкиятенә ияреп.*

*(Татар халык әкияте буенча)*

Катнашалар: Карт, карчык, кыз, куян, төлке, бүре, аю, көтүче, сандугач.

Автор: Борын-борын заманда яшәгән, ди, Карт белән карчык. Аларның булган ди үги кызлары. Аның уңганлыгына, аның булганлыгына кешеләр сокланып туя алмаганнар. Үги ананың моңа бик ачуы килгән.
Карчык: Бар, бу кызыңны урманга илт. Адаштыр. Өйгә аны бүтән алып кайтма.
Автор: Карт белән кыз урманга киткәннәр.
Бергә: Мин барам урманнан
Як-ягыма каранам.
Тирә-як бик матур,
Мин шуңа сокланам.
Карт: Бар, Кызым, син җиләк җый, мин утын әзерлим.
Кыз: (җиләк җыя) Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән?
Уф, арыдым. Әти, әтием, минем тарысым тулды.
Автор: Ә әтисе күптән кызны калдырып авылга кайтып киткән.
1телем ипи кисәген чыгарып ашамакчы була, аның каршысына Куян килеп чыга.
Куян: Бик талчыктым, түтәкәй,
Бик ачыктым, түтәкәй,
Бирче азрак ипекәй.
Бирче азрак ипекәй.
Кыз. Мә, Куян, авыз ит.
Куян: Яхшылыкка – яхшылык. Мә сиңа куян бүреге.
Кыз. Рәхмәт.

Куян киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Төлке килеп чыга.

Төлке: Бик талчыктым, түтәкәй,
Бик ачыктым, түтәкәй,
Бирче азрак ипекәй.
Бирче азрак ипекәй.

Кыз. Мә, Төлке, авыз ит.

Төлке: Яхшылыкка – яхшылык. Мә сиңа төлке туны.

Кыз. Рәхмәт.

Төлке киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Бүре килеп чыга.

Бүре: Бик талчыктым, түтәкәй,
Бик ачыктым, түтәкәй,
Бирче азрак ипекәй.
Бирче азрак ипекәй.

Кыз. Мә, Бүре, авыз ит.

Төлке: Яхшылыкка – яхшылык. Мә сиңа бүре итеге.

Кыз. Рәхмәт.

Бүре киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Аю килеп чыга.

Аю: Бик талчыктым, түтәкәй,
Бик ачыктым, түтәкәй,
Бирче азрак ипекәй.
Бирче азрак ипекәй.

Кыз. Мә, Аю, авыз ит.

Аю: Яхшылыкка – яхшылык. Мә сиңа тәмле бал.

Кыз. Рәхмәт.

Аю киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Көтүче килеп чыга.

Көтүче: Бик талчыктым, түтәкәй,
Бик ачыктым, түтәкәй,
Бирче азрак ипекәй.
Бирче азрак ипекәй.

Кыз. Мә, Көтүче, авыз ит.

Көтүче: Яхшылыкка – яхшылык. Мә сиңа 1 мал.

Кыз. Рәхмәт.

Көтүче киткәч, калган икмәк сыныкларын ашыйм гына дисә, Сандугач очып килгән.

Сандугач: Бик талчыктым, түтәкәй,
Бик ачыктым, түтәкәй,
Бирче азрак ипекәй.
Бирче азрак ипекәй.

Кыз. Мә, Сандугач, авыз ит.

Сандугач: Яхшылыкка – яхшылык. Матур кыз, нинди теләгең бар, хәзер үтим.

Кыз: Минем өйгә кайтасым килә, әткәемә генә барып хәбәр салчы, Сандугачым.

Сандугач: Хәзер, хәзер, матур кыз.

Кош очып киткән. Әтисенә хәбәр салган. Әтисе кызын барып алган. Шуннан бирле үги кыз матур гына гомер итә, ди.

## *“Өч кыз” әкиятенә ияреп.*

*(Татар халык әкияте буенча)*

Катнашалар: Автор, әни, тиен, 3 кыз, 3 малай.

Автор.Бер хатынның өч кызы була. Кызлары бәхетле булсын өчен ул эшли дә эшли.(әнисе эшли)

Менә кызлар зур үсәләр. Алар барысы да матур, барысы да сылу. (кызлары басалар) Кызлар кияүгә чыгалар да еракларга китәләр. (малайлар чыгып алып китәләр)

Берзаман әниләре авырый башлый. Ул тиенне чакыра.

Әни. – Тиен, дустым, кызларыма әйт әле, хәлем начар.

Автор. Тиен әбинең олы кызына урман аша китә.

Тиен. – Мин барам, барам, барам.
Урманнан барам, барам.
Әйе шул, шулай шул,
Урманнан барам, барам.

Автор. Кыз өйдә була. Ул табак чистарта.

Тиен. - Әй, сылу кыз. Синең әниең авырый. Ул сине үзе янына чакыра.

1кыз. – Бара алмыйм, вакытым юк.

Тиен. – Син ташбака бул.

Ташбака белән уен.

- Су буенда бакалар,
  Баталар да калкалар,
  Уңга да борылалар,
  Сулга да борылалар.
  Сикереп тә алалар
  Баталар да калкалар.

Автор. Тиен икенче кызга китә.

Тиен. - Әй, сылу кыз. Синең әниең авырый. Ул сине үзе янына чакыра.

2кыз. – Һай бара алмыйм, вакытым юк.

Тиен. – Син үрмәкүч бул.

Үрмәкүч белән уен.

Автор. Тиен өченче кызга китә.

Тиен. - Әй, сылу кыз. Синең әниең авырый. Ул сине үзе янына чакыра.

3кыз. – Хәзер, хәзер тиен дус.

Автор.- Сылу кыз урман буйлап тиен бергә әнисе янына ашыга.

– Мин барам, барам, барам.
Урманнан барам, барам.
Әйе шул, шулай шул,

Урманнан барам, барам.
3кыз. – Әнием, мин килеп җиттем.
Әни. – Рәхмәт, кызым.
Тиен. – Син бик яхшы бала. Бәхетле бул, яхшы яшә. Кешеләр сине яратырлар, сине онытмаслар.
3кыз. Рәхмәт тиен дус.
Автор. – Чыннан да, Сылу кыз һәм әнисе бик озак һәм бәхетле яшәгәннәр. Шуның белән экияттә тәмам.

## *Габдулла Тукай безнең күңелләрдә.*

1бала: Исәнләшеп әүвәл сезнең белән
Бисмилланы әйтеп эчемнән
Басып торабыз алдыгызда
Бәхет нурларына төренеп.

2 бала:Туган телне яттан сөйләп,
Үсеп җиткәнбез шулай.
Барлык татар балалары
Ярата сине, Тукай.

3 бала:Апрель җитсә, исемеңне
Җырына куша тургай.
Милләтемнең кояшы син
И моңлы, нурлы Тукай!

4 бала:Әкиятләрен сөйләп, тыңлап,
Телләребез ачыла.
«Су анасы», «Шүрәлеләр»-
Безнең дуслар барсы да.

5 бала:Иң кадерле, иң газиз тел
Ул үз телең – туган тел!
Әби-бабаң, эткәң-әнкәң,
Син сөйләшә торган тел!

Тәрбияче:Нинди таныш моңлы көй бу?
Балалар: Тукай җыры - «туган тел».
Тәрбияче: Истән бер дә чыкмый торган
Халык көе «Туган тел».

Җыр «Туган тел»

Тәрбияче: Карагыз әле, балалар, монда нинди матур китап бар. Г.Тукай «Әкиятләр» дип язылган. Сез экиятләр яратасызмы?

Алайса әйдәгез, әкиятләр иленә сәяхәткә киттек.

*Тапкырларга беренче табышмак.*

«Нәкъ кеше кебек үзе
Маңгаенда бар мөгезе.
Ә шулай да шаккатыра
«Былтыр кысты! – дип кычкыра.
Туганнарын чакыра. Кем ул?» (Шүрәле)

Шүрәле.

Шүрәле тыккан кулын –
Селкенмидер, кузгалмыйдыр;
Белми инсан хәйләсен –
Һич балтага күз салмыйдыр.

Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп,
Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп.
Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра,
Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра....

Шүрәле: Кысты, харап итте явыз Былтыр мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине.

Тәрбияче: Ачык авыз син Шүрәле. Балалар, әйдәгез Тукайның яраткан татар халык уены “Ачык авыз” уйныйбыз. Ачык авыз – Шүрәле.

Уен «Ачык авыз»

*Тапкырларга икенче табышмак.*

Туннарга киендерә.
Җылыта, сөендерә,
Тоягы була ярык,
Исеме аның... (Сарык)

Кәҗә белән сарык.

Борын заман бер Ир белән Хатын торган,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык, -
Болар булган берсеннән дә берсе арык.
Нишли инде мискин Кәҗә белән Сарык?
Икесенә бер зур гына капчык тегеп,
Китте болар кырга таба сәфәр чыгып.
Бара болар. Күпме баргач, алла белә,
Юл өстендә үлгән Бүре башын таба.

Тәрбияче: *Тапкырларга өченче табышмак.*

«Кем сакаллы булып туа?» (Кәҗә)

Гали белән кәҗә.

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый – сакалын селкетә.

Тәрбияче: *Тапкырларга дүртенче табышмак.*

«Кычкырадыр: «Качма! Качма! Тукта, тукта, и карак!
Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!» (Су анасы)

Су анасы.

- Су анасы мин, китер,
Кайда минем алтын тарак?
Бир! Бая көндез алып качты
Синең угълың, карак!
Төшкән айның шәүләсе мин юрган астыннан карыйм;
Калтырыйм, куркам: “Ходай! – дим,-
Инде мин кайда барыйм?”
Һич өзлексез шык та шык! Безнең тәрәзәне кага;
Ул котычкыч сачләреннән чишмә төсле су ага...

Тәрбияче: Балалар, Су анасының алтын тарагы белән бер генә уйнап алыйк.

Уен «Таракны бир».

Тәрбияче: Алтын тарак кемдә кала,
Шул табышмак җавабын таба.

1. Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт?
Я әйтеп кара! ( Яз)

2. Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште,
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.
Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,
Бу кайчан була? (Җәй)

3. Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана,
Бу кайчан була? (Көз)

4. Һәр җир карланган,
Сулар бозланган,
Уйный җил-буран,
Бу кайчан, туган? (Кыш)

Малай: Мә, Су анасы сиңа, алтын тарак,
Бер кайчан да булмам мин явыз, карак.

Тәрбияче: *Тапкырларга бишенче табышмак.*

«Кешенең якын дусты
Йортның тугры сакчысы.
Аннан гел игелек көт,

Ә исеме ничек?» (Эт)

Кызыклы шәкерт.

Шәкерт:Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!
Акбай: Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.
Юк кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.
Шәкерт: - Ах, җүләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул:
Картаеп каткач буыннар – эш белү уңгайсыз ул!
Тәрбияче: *Тапкырларга алтынчы табышмак.*
Чуар, йомшак күлмәге,
Тотсаң уңа бизәге.
Тоттырмый, китә очып,
Я кала җирдә посып. (Күбәләк)

Бала белән күбәләк.

Бала: Әйт әле Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек?
Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

Күбәләк: Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда.
Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.
Бала. Юк, үлмәдең, Тукай, син мәңге яшь. Син мәңге безнең арада.
Мәңге көләч шигырьләреңнән без, Туган халкым, кодрәт, көч ала.
Тәрбияче: Булдырдыгыз, балалар. Сез Тукай шигырьләрен, әкиятләрен укып, яраткан җырларын җырлап, тормыш сабагы аласыз. Изге туган телебезгә, татар теле Тукай теленә тугры булып үсәсез. Сез яшь Тукайчылар.

## ***«Сертотмас үрдәк» әкиятенә ияреп.***

*(А.Алиш буенча)*

Катнашалар: Йорт хуҗасы, эт, үрдәк, әтәч, тавыклар, кәҗә, песи, керпе, куян, аю, күке, күбәләк, бүре, төлке, төлке балалары.

Автор: Борын-борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер Үрдәк булган. Бу үрдәк озак-озак итеп, яңа хәбәрләр сөйләргә бик ярата икән. Беркөнне Йорт хуҗасы үзенең этен ияртеп урманга барырга булган.
Йорт хуҗасы: Мин Актырнак белән урманга утын кисәргә барам. Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәгез.
Эт: Һау-һау. Берәүгә дә белдермәгез.

*Йорт хуҗасы белән Актырнак урманга китәләр.*

Кәҗә: Мә-мә. Инде хәзер нишләргә?
Үрдәк: Бак-бак-бак. Нигә белдермәскә кушты икән?
Песи: Мияу-мияу.Икенче көнне дә кайтмас бу.
Тавыклар: Кыт-кытыйк. Алып кайтыйк. Кыт-кытыйк.
Әтәч:Кикерикүк. Үрдәк син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар! Берәүгә дә белдермә.
Кәҗә: Мә- мә- белдермә.
Үрдәк: Бак-бак-бак. Ярар, сезнең өчен генә барсам барырмын инде.
Әтәч: Исән йөр.

*Үрдәк урманга китә.*

Үрдәк: Мин барам урманга
Як-ягыма каранам
Керпе: Кая барасың болай?
Үрдәк: Бак-бак-бак. Сәлам керпе. Урманда утын кисүче Хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез, Актырнак та аңа ияреп киткән иде. Йорт-җирне саклаучы юк. Аларны эзләргә иптәшләрем мине җибәрделәр.
Керпе: Синең өең еракмы соң?
Үрдәк: Юк ерак түгел.
Керпе: Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы? Нык ашыйсы килә.
Үрдәк: Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара! Еланнар да тычканнар да юк.
Керпе:Син үрдәк саграк бул. Очраган берәүгә сереңне сөйләмә. Йортың тыныч булыр.

Үрдәк: Мин барам урманнан
Як-ягыма каранам.
Тирә-як бик матур
Мин шуңа сокланам.

Куян:Әй, бүрекле үрдәк, көзге төсле матур, кыр төсле зур күл булганда ни эшләп урманда йөрисең?
Үрдәк: Бак-бак-бак. Сәлам куян. Урманда утын кисүче Хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез, Актырнак та аңа ияреп киткән иде. Йорт-җирне саклаучы юк. Аларны эзләргә иптәшләрем мине җибәрделәр.

Куян: Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга кирәк.
Үрдәк: Нәрсә дисең?
Куян: Синең өең еракмы соң?
Үрдәк: Юк ерак түгел.
Куян: Хуҗаңны күргәнем юк. Сау бул.

Үрдәк: Мин барам урманнан
Як-ягыма каранам.
Тирә-як бик матур
Мин шуңа сокланам.

Аю, аю уян инде. Урманда утын кисүче Хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез, Актырнак та аңа ияреп киткән иде. Йорт-җирне саклаучы юк. Аларны эзләргә иптәшләрем мине җибәрделәр. Күрмәдеңме?
Аю: Күрмәдем. Урман эченәрәк керсәң, табарсың. Әһе, Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга кирәк.

Үрдәк: Мин барам урманнан
Як-ягыма каранам.
Тирә-як бик матур
Мин шуңа сокланам.
Бүре: Әй, бүрекле баш, шушындый куе урманда ялгызың, курыкмыйча, ни эшләп йөрисең?
Үрдәк: Бак-бак-бак. Сэлам бүре. Урманда утын кисүче Хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез, Актырнак та аңа ияреп киткән иде. Йорт-җирне саклаучы юк. Аларны эзләргә иптәшләрем мине җибәрделәр.
Бүре: Андый кешене күргәнем юк. Сарыкларын ашап кайтырга кирәк.

Үрдәк: Мин барам урманнан
Як-ягыма каранам.
Тирә-як бик матур
Мин шуңа сокланам.
Үрдәк: Әй, кошлар, урманда утын кисүче Хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез, Актырнак та аңа ияреп киткән иде. Йорт-җирне саклаучы юк. Аларны эзләргә иптәшләрем мине җибәрделәр. Күрмәдегезме?
Күке: Юууук, юууук.
Күбәләк:Сак бул, сак бул.

Үрдәк: Мин барам урманнан
Як-ягыма каранам.
Тирә-як бик матур
Мин шуңа сокланам.
Үрдәк: Багалмакай, матур апакай урманда утын кисүче Хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез, Актырнак та аңа ияреп киткән иде. Йорт-җирне саклаучы юк. Аларны эзләргә иптәшләрем мине җибәрделәр. Күрмәдеңме?

Төлке: Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре, күрдем мин аны! Янындакәкре койрыклы эте дә бар иде. Әйдә минем белән.

1төлке баласы: Әни, безгә азык алып кайттыңмы?

Төлке: Әйе, бәбкәләрем. Менә сезгә тәмле азык. Ә мин авылга барам, анда азык бик күптер.

2төлке баласы: Күбрәк алып кайт.

3төлке баласы: Үзең дә тиз кайт.

Автор: Авылга китеп балалары янына төлке  кире әйләнеп кайта алмаган шул. Йорт хуҗасының капканына эләккән. Хайваннарда сертотмас үрдәккә шундый зур эш кушуларына үкенгәннәр.

# Кулланылган әдәбият


1. Татарча сөйләшәбез: 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. – Казан: Татарстан Республикасы “ХӘТЕР” нәшрияты, 2011. – 56 б.
2. Татарча сөйләшәбез: “Минем өем” 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча аудио-кушымта, - Казан: “АКСУ” компаниясе, 2011.
3. Татарча сөйләшәбез: 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. – Казан: Татарстан Республикасы “ХӘТЕР” нәшрияты, 2012. – 71 б.
4. Татарча сөйләшәбез: “Уйный-уйный үсәбез” 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча аудио-кушымта, - Казан: “АКСУ” компаниясе, 2012.
5. Татарча сөйләшәбез: 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик кулланма/ [авт.:Зарипова һ.б.]. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. – 72 б.
6. Татарча сөйләшәбез: “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча аудио-кушымта, - Казан: “АКСУ” компаниясе, 2012.
7. Туган телдә сөйләшәбез: 2-3 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик кулланма өчен аудио-кушымта, - Казан: “АКСУ” компаниясе, 2012.
8. Туган телдә сөйләшәбез: 3-4 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик кулланма өчен аудио-кушымта, - Казан: “АКСУ” компаниясе, 2012.
9. Алиш Абдулла “Ана әкиятләре”. Әкиятләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003. – 55 б.
10. Гарипова Д.Ф., Фатихова И.М. «Мы любим театр» Дополнительная образовательная авторская программа для детей старшего дошкольного возраста. – Набережные Челны: ГОУ ВПО «НГПИ», 2009. – 53 с.
11. Гарипова Әнүзә “Тел ачкычы”. – Чаллы, “Хәерле иртә!” нәшр., 1996. – 112 б.
12. Закирова К.В.“Иң матур сүз”. Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.
13. Тукай Габдулла Мәсәлләр. – Казан: Мәгариф нәшрияты, 2004. – 16 б.
14. Тукай Габдулла Шигырьләр, экиятләр, поэмалар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1990 – 255 б.
15. Шәрифуллина Г.К., Габдрахимова Ә.Х. “Әйдәгез, экиятләрдән башлыйк”. – Яр чаллы, – 2011. – 40 б.
16. Ягъфәров Р. “Татар балалар фольклоры”. – Казан: “Раннур” нәшрияты, 1999. – 352 б.

(алфавит тэртибендэ)

Прошито, пронумеровано и скреплено
печатью 35 страниц

«28» 08 2015 г.

Заведующий Е.Х. Яруллина